СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Габделхая Каримова, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Габделхәй Кәримов урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
Шушмабаш авыл җирлеге Советы карары

«11» март 2026 ел **№ 18**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге Советының норматив хокукый актларын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, Шушмабаш авыл җирлеге Советы карар КАБУЛ ИТТЕ:

1. Шушмабаш авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- “Арча муниципаль районының “Шушмабаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру тәртибен раслау һәм Арча муниципаль районының “Шушмабаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү турында” 2017 елның 14 сентябрендәге 46 номерлы карар.

- “Арча муниципаль районының “Шушмабаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр керту һәм Арча муниципаль районының

“Шушмабаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм Шушмабаш авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 сентябрендәге 46 номерлы карары белән расланган контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларына мәгълүмат бирү турында” 2021 елның 3 августындагы 37 номерлы карар.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы **В.В.Сәгыйтов**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ОГРН 1161690092110 * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ * ШУШМАБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ
СОВЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609012678